РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/


**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**№ 18** **« 10 » апреля 2017 г.**

Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 24 мартындагы 554-р номерлы «Урман утырту көне» Республика табигатьне саклау акциясен үткәрү турында» боерыгын тормышка ашыру турында

Урманга сакчыл караш тәрбияләү, җәмәгатьчелек игътибарын урман ресурсларын саклау, яңадан торгызу һәм арттыру проблемаларына җәлеп итү, шулай ук Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан урманнарда уңай санитар-экологик хәл булдыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 24 мартындагы 554-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә,

1. Район Башкарма комитетына, авыл җирлекләре башкарма комитетларына, "Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы" ДБУ (Закирова Г. М.), "Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы" ДБУ (Сәгъдиев А. Н.) белән берлектә:

- 2017 елның 29 апрелендә «Урман утырту көне»традицион республика табигатьне саклау акциясе кысаларында чаралар үткәрүне оештырырга;

- тиешле эшләр башланыр алдыннан хезмәт куркынычсызлыгы буенча максатчан инструктаж үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр хезмәт коллективларына, гражданнарга урман фонды җирләре составындагы урман кишәрлекләрендә урман утыртмалары (культуралар) салуда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә районның яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән берлектә «Урман утырту көне» республика табигатьне саклау акциясендә катнашырга тәкъдим итәргә.

4. «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләче-информ» мәгълүмат үзәгенә акцияне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны, урманга сак караш турында материаллар бастыруны һәм чыгаруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башлыгы урынбасары А. Г. Фәтхуллинга йөкләргә.

И. Ф. Зарипов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕГЕ